**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423740,село Актаныш, проспект Ленина,дом 58,тел.3-44-40

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-44-40

**КАРАР**

№2 «26» февраль 2021 ел

## Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 ел, №22 «Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 ел, №22 «Актаныш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Актаныш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш авыл җирлеге
Советы рәисе

Э.Н.Фәттахов